Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге Советы

**КАРАР №12**

Юлсубино авылы 2024 елның 10 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

- мәет җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру;

-җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге хезмәтләре сыйфатына карата таләпләрне раслау;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау;

- ире, якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булган кешенең законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкин булмаганда вафат булганнарны (һәлак булганнарны) җирләүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау, шулай ук өйдә, урамда яисә шәхесенең эчке эшләр органнары билгеләгәннән соң башка урында үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда;

- шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне (һәлак булганнарны) күмүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау.

2. Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары

белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, йорт №56 а һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Юлсубино авыл җирлеге башлыгы

